**«МОҢНАР ТУЛА КҮҢЕЛГӘ»**
**Мирһади РАЗОВ**
**иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция**
*(өлкән сыйныф укучылары өчен)*

*Кичәнең башыннан ахырынача талгын гына көй ишетелә,*
*сәхнәгә ике алып баручы чыга.*

**1нче алып баручы:**

...Бу – туган җир.
Иң кадерле,
Иң бөек һәм изге җисем.
Бу – туган җир. Аңлый алган
Күңелләрнең бөтен гамен,
Юатучы кайгылардан
Биреп бөтен җанын-тәнен.

**2нче алып баручы:**

Бу – туган җир. Шатланучы
Безнең нәни сөенечкә.
Яхшы булмый мөмкинме соң?
Шундый җирдә туып үс тә?!
Бу – туган җир. Кеше иткән,
Йөрәкләргә моңнар биргән.
Гомерлеккә аерылмас
Бала бит без туган җирдән.

«*Бу – туган җир*»

**1нче алып баручы:**Хәерле көн, исәнмесез!?Туган ягы, туган авылы табигатеннән илһам алып яшәмәгән, иҗат итмәгән шагыйрьне, әдипне шигъърият һәм әдәбият белми. Булачак шагыйрь, язучы өчен болыннарда, тугайларда, кырларда, әрәмәлектә, су буйларында аунап-тәгәрәп үсү иң беренче кирәкле шарт булып тора. Бүгенге кичәбездә сез шагыйрь Мирһади Разовның шигырьләрен, җырларын тыңларсыз.

*Көй көчлерәк яңгырап ала.*

**2нче алып баручы:**

Гомер матур,
Гомер – рәхәт мизгел.
Гомер бүләк безгә вакыттан.
Ялкын булып, давыл булып яшик,
Үкенмәслек итеп актыктан.
Гомер буйлап елгыр еллар чаба
Ак хыяллар, уйлар ягына.

Җиргә җылы биргән гомер, сүнгәч,
Күктә йолдыз булып кабына.

*«Гомер»*

*Көй көчлерәк яңгырап ала.*

**1нче алып баручы:**

Хыялым белән очам
Җиде күкләр катына.
Йолдызлар серен тыңлап,
Кайтам уйлар атында.

Гашыйкмын туган җиргә,
Шагыйрь җаны ирекле!
Тыялмыйм хисләремне –
Мин яратам хөрлекне.

Моң ята йөрәгемдә –
Үксеп-үксеп еларлык.
Җаным шигъри гамь тулы,
Давылларга чыдарлык!

*Көй көчлерәк яңгырап ала.*

**2нче алып баручы:** Шагыйрьләр – хисле, серле халык, кирәк икән, алар бала күңелле дә була алалар.

*Талгын гына көй астында укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Тик бер генә тапкыр күрдем –
Шул диңгезне сагынам.
Акчарлаклар булып төштә
Дулкыннарга кагылам.

Диңгезче булам үскәч мин,
Зур корабта йөзүче.
Давыллар белән көрәшеп
Дәрьяларны гизүче.

Хыялый малай димәгез,
Яратам шул диңгезне.
Үсеп җиткәч корабыма
Утыртырмын мин сезне.

*«Диңгезче булам»*

**2нче укучы:**

Сабантуйга әзерләнәм –
Һәр көн иртән йөгерәм,
Көч артсын, дип гер күтәрәм,
Бар эшкә дә өлгерәм.

Көрәшәсем килә минем
Сөлге тотып кулыма.
Әти әйтә, батыр булу
Килешер, дип улыма.

Күрше кызы гына мине
Үчекләп үрти, көлә.
Сабантуйда шул кызыйны
Шаккаттырасым килә.

«*Батыр буласым килә*»

**3нче укучы:**

Уңган малай булганга,
Үтәгәнгә һәр эшне
Бүләк итте әтием
Бик матур кәләпүшне.

Кәләпүшем чигелгән,
Кояшта җем-җем килә,
Горурлыгым ул минем
Аны һәр татар белә.

Кәләпүшем киям дә
Көн саен дога кылам:
«Син яшәсәң, милләтем,
Мин дә бәхетле булам».

«*Кәләпүшем*»

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Күңелләрне җилкендерә
Ярсулы язгы айлар.
Зәңгәр күктә шатлык теләп,
Җырын суза тургайлар.
*Кушымта:*
Миндә туган халкым йөрәгенә
Җырларымнан якты юл салам.
Нәни тургай синең сайравыңнан

Яшәү дәрте, кайнар моң алам.

Җырларымны алып китсен
Дусларыма яз җиле.
Чакырам матур бәйрәмгә
Көтә сезне Чаллы – җыр иле.
*Кушымта.*

Җырлыйк, бергә дус-ишләрем
Җырларның яңаларын.
Ташып аксын моң чишмәсе
Без тургай балалары.
*Кушымта.*

«*Без тургай балалары*»
*(Мирһади Разов сүз., Эльмира Галимова көе)*

**1нче алып баручы:** Мирһади Мирзаян улы Разов 1960 елның 22нче октябрендә Татарстан Республикасының Актаныш районы Аеш авылында туган. Авылда сигезьеллык мәктәпне тәмамлап, Актанышта урта белем ала. Мәктәптә укыганда ук әдәби иҗат эше белән кызыксына, шигырьләр яза. Алар район газетасы битләрендә һәм «Ялкын» журналы битләрендә дә басылып чыга.

**2нче алып баручы:** Мирһади Мирзаян улын Сөн буйлары, әрәмәлекләр, авылының сихри матурлыгытабигать баласы итеп үстергән. Табигать үз баласына бәхетне мулдан биргән. Аның шигырьләре җырлап тора.

Җимешләрен кошлар чүпли,
Кызарып пешкән миләш.
Җанда миләш әчеләре –
Миңа кем бирер киңәш.
Өзеп миләш тәлгәшләрен,
Кададым чәчләремә.
Белмәдем аерыласын,
Чыланып яшьләремә.

**1нче алып баручы:** Мирһади Разов «Кызыл миләш», «Мәк чәчәкләре», «Ашкынам күрергә». Шуларга өстәп бик яратып җырлана торган «Җиләкле җәй» җырлары авторы:

...Ак каеннар арасына
Килгән идем җиләккә,
Очрадың да, гашыйк иттең
Ялкын салдың йөрәккә.

Эх, җиләкле җәйләрнең
Оныталмамын ямен.
Тоямын иреннәреңдә
Каен җиләге тәмен.

**2нче алып баручы**: «Җиләкле җәй» шигыренә көйне Рөстәм Хәйруллин язган. «Мәхәббәт килгән икән», «И, кадерле туган як». Ә «Әфган җиле» шигыренә көйне Фәрит Миңлебаев иҗат иткән.

...Әфган җиле исә, әфган җиле
Безнең йөрәкләрне телгәләп.
Яуда ятып калды якын дуслар,
Кайталмадык илгә бергәләп.

**1нче алып баручы:**: «Әнкәй гөле» җырын барыгызда беләсез.
...Авыр чакта киләм гөл каршына
Әнкәй тора сыман елмаеп.

**2нче алып баручы:** «Ашкынам күрергә», «Иркәмә», «Әй, халкымның гүзәле», «Сылу кызга», «Сөйгән ярын көтә кызлар», «Әрәмәдә – карама» (Әхтәм Миңлебаев көе)

Әрәмәдә – карама
Күзкәйләрең кара ла.
Кояш кебек йөзләреңнән
Сөю нуры тарала.

**1нче алып баручы:** Чаллы гимнына әйләнгән «Чаллы сиреньнәре» җырының авторы Мирһади Разов. Җырлар исемлеге шактый. Алар «Җиләкле җәй» исемле китап булып дөнья күрделәр.

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Сандугачлар оя кора,
Кама буе – таллы яр.
Тибрәлә моң канатында
Таң атканда Чаллыяр.
*Кушымта:*
Чаллыяр,
Чаллы,Чаллы, Чаллыяр.
Чынга аша синдә безнең
Иң-иң якты хыяллар.

Урамнарың нуры булып
Үсә зифа каеннар.

Кыя булып күтәрелә
Ак йортларың, Чаллыяр.
*Кушымта.*

Күкләреңдә арта һәр көн
Йолдызларның яңасы.
Яшь йөрәкләр парын таба,
Син – гашыйклар каласы.
*Кушымта.*

Язмышыңны байрак итеп,
Яшьлек тоткан кулына.
Бәхет төяп «КамАЗ»ларың
Чыга илем юлына.
*Кушымта.*

«*Чаллыяр*»
*(Мирһади Разов сүз.,Фәрит Миңлебаев көе)*

**2нче алып баручы:** 1979 елда Мирһади Разов Чаллы шәһәренә килеп урнаша һәм КамАЗда эшли башлый. Бер үк вакытта, читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укый. Чаллыда «Нур» газетасы чыга башлагач, яшь журналистны бирегә эшкә чакырып алалар, ул әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Аның бер бәйләм шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1988), «Ләйсән» − моңлы бишегебез» (2009),«Әдәби Чаллы » (2014) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күргән.

**1нче алып баручы:** 1990 елларда Мирһади Разов Чаллы телевидениесендә «Кыйбла», «Әйлән-бәйлән», «Чаллы утлары», «Шигъри дулкын» кебек дини-мәдәни һәм әдәби темаларны яктырткан тапшырулар алып бара. Хәзерге вакытта «Шәһри Чаллы» газетасының баш мөхәррире.1996 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**2нче алып баручы:**

Әгәр җилләр исеп тормый икән,
Пыскып яна учак ялкынсыз.
Гомерләргә безнең җан өрүче
Илаһи зат-гүзәл хатын-кыз!

Әгәр якты кояш елмаймаса,
Эрер иде микән язын боз?
Күңелләрне эретерлек итеп
Балкый ала бары хатын-кыз!

Җир шарының ак бәхете өчен
Яратылган җәүһәр, алтын сез:

Әнкәй, апа, сеңел һәм сөйгән яр –
Безне җылытучы ялкын сез!

*«Мәдхия»*

*Көй көчлерәк яңгырап ала.*

**1нче алып баручы:**

Өй түрендә яран гөлем
Шау чәчәккә күмелгән.
Исемеңне җырга салып,
Көйләп йөрим күңелдән.

Көннәремнең, төннәремнең
Кояшы син, ае син.
Яшәү дәрте биреп торган
Йөрәгемнең мае син.

Бакчабызда сайрый былбыл
Үзәккәе өзелә.
Сүзең татлы, йөзең якты,
Күз тимәсең үзеңә.

Тәрәзәдән ак сиреньнәр
Карый безгә үрелеп.
Аерылмыйча яшик, җаным,
Мәхәббәткә төренеп.

*«Йөрәк маем»*

**2нче алып баручы:**

...Күкнең хәтта кояшы да,
Ае да, йолдызы да,
Тиңләшә алмый, Әнкәй –
Син – гади җир кызына.

Ак каеннар кебек сабыр,
Ак уйлы, саф күңелле.
Имәннәрдәй курку белмәс
Йөрәкле син түгелме?!

Авыр чакта исемең дә
Зур дәва җаннарыма...
Әнкәем, мин башым иям
Тик синең алда гына!

*«Әнкәйгә»*

*Җыр башкарыла.*

**ҖЫР:**

Чит җирләрдә гомер кичерәбез,
Тынгы бирми сагыш йөрәккә.
Сагынганда гына карарсыз, дип
Гөл җибәргән әнкәй бүләккә.
*Кушымта:*

Гөл җибәргән, гөл җибәргән,
Әнкәй боекмагыз,
Йөремәгез, диеп моңаеп.
Авыр чакта киләм гөл каршына
Әнкәй тора сыман елмаеп.

Әнкәй гөле һәрчак яшел килеш
Күз карашы кебек саклыйбыз.
Өебездә шушы гөлдән изге
Кадерлерәк әйбер тапмыйбыз.
*Кушымта.*

Чәчәк аткан саен сөенәбез,
Җаныбызга тула нур, рәхәт.
Үзең кебек безгә сөеп баккан
Гөлең өчен әнкәй, мең рәхмәт.
*Кушымта.*

*«Әнкәй гөле»*
*(Мирһади Разов сүз., Виталий Агапов көе)*

**1нче алып баручы:** Шагыйрь Мирһади Разов бәхетле язмышка ия. Аның шигырь, җырлары мәңгелек. Ул беркемне кабатламый, үз сүзе, үз йөзе, үз каләме бар.

Актанышның юлларына
Кемнәр сипкән вак ташлар?
Чит җирләрдә хәл белешеп
Яшик бергә, якташлар.

Туган якны юксынудан
Моңнар тула күңелгә.
Җыелышса якташларым
Дөнья нурга күмелә.

Агыйделнең ак томаны
Тараладыр таңнарда.
Якташларның җылы сүзе
Дәва була җаннарга.

Бер-беребезгә терәк булсак
Ятлар безне какмаслар.
Актанышның данын яклап
Гомер итик, якташлар.

**2нче алып баручы:** Мирһади Мирзаян улы Разов − хисле шагыйрь. Аның моңнары күңелләренә генә түгелеп калмасын, киләчәктә дә, без, укучыларын, сөендереп, ак кәгазь битләрендә урын алсын. Уңышлар сезгә.

## Файдаланылган әдәбият


Разов, М. Моңлы биләү: шигырьләр / М. Разов. − Яр Чаллы: КАМАЗ, 1993. − 128 бит.

Разов, М. Җиләкле җәй: җырлар (ноталары белән) / М. Разов. − Яр Чаллы: КамАЗ, 2003. − 48 бит.